| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**23/10/2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ __2685________** |

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында

2013 елның 05 апрелендәге«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә гомуми таләпләрне раслау хакында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба - Таләпләр) әлеге карарга кушымтада каралганча расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль заказы дирекциясе» муниципаль казна учреждениесенә, әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, Таләпләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http:/.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
__________________ № ____________

# Зеленодольск муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләр

1. Әлеге документ 2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә гомуми таләпләрне раслау хакында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары (алга таба - Гомуми таләпләр) нигезендә эшләнгән Зеленодольск муниципаль районының хокукый актларын эшләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәүне тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба - Таләпләр) билгели.

а) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәгеләрен раслый:

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен (алга таба - норматив чыгымнарны);

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль органнары, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләренә)таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен;

б) муниципаль органнарның түбәндәгеләрен раслый:

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны;

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм алар ведомствосындагы органнар тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләренә) таләпләр.

2. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектлары формасында эшләнә.

Әлеге Таләпнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, аның карамагындагы муниципаль казна, бюджет учреждениеләре өчен Зеленодольск

муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектлары рәвешендә эшләнә.

Әлеге Таләпнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Совет аппараты өчен Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карарлары (күрсәтмәләре) проектлары рәвешендә эшләнә.

Әлеге Таләпнең 1 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органнары өчен Зеленодольск муниципаль районының тиешле муниципаль органнары вазыйфаи затларының боерыклары (күрсәтмәләре) проектлары рәвешендә эшләнә.

3. Әлеге Таләпнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар проектлары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет утырышларында (алга таба - Совет) мәҗбүри рәвештә алдан фикер алышырга тиеш

4. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек контроле максатында фикер алышу өчен, Гомуми таләпләрнең 6 пункты, күрсәтелгән хокукый актлар проектлары һәм аларга аңлатма язуы, аларны әзерләгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль органнар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә әлеге таләпләрнең 5 пунктында билгеләнгән срокка бердәм мәгълүмат системасына урнаштыралар.

5. Җәмәгатьчелек контроле максатларында фикер алышу срогы «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмати системада 1нче пунктта күрсәтелгән хокукый актлар проектлары урнаштырылган көннән алып ун календарь көн тәшкил итә.

6.Муниципаль органнар әлеге Таләпләрнең 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясенең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән органнар тарафыннан билгеләнгән срокта электрон яки язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен карыйлар.

7. Муниципаль органнар иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен караган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге тәкъдимнәрне һәм аларга җавапларны билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

8. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча, кирәк булганда, җәмәгать контроле максатларында, әлеге Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына үзгәртү турында , җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен исәпкә алып һәм Гомуми таләпләрнең 3 пункты һәм әлеге Таләпләрнең 3 пункты нигезендә Совет утырышларында хокукый актлар проектларының әлеге таләпләренең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән таләпләрне карау турында карар кабул ителә.

9. Әлеге Таләпләр 1 пунктының «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау нәтиҗәләре буенча Совет түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында;

б) хокукый акт кабул итү мөмкинлеге турында.

10. Хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында Совет бәяләмәсе алынган очракта, муниципаль органнар күрсәтелгән проектны, Совет искәрмәләрен исәпкә алып, өч эш көненнән дә соңга калмыйча эшләп бетерәләр һәм кабат Советка җибәрә.

11. Советтан уңай бәяләмә алган очракта, муниципаль орган хокукый акт проектын раслый.

12. Совет кабул иткән карар, барлык әгъзалары имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча Муниципаль орган тарафыннан Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырыла

13. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган хокукый актлар елына кимендә бер тапкыр яңадан карала. Күрсәтелгән хокукый актларны яңадан карау түбәндәге карарларның берсе кабул ителә торган Совет утырышларында гамәлгә ашырыла:

а) хокукый актны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында;

б) хокукый актка үзгәрешләр кертү кирәклеге булмау турында.

14. Әлеге Таләпләрнең 9 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, муниципаль органнар Совет кабул иткән карарлар нигезендә эшләп бетергәннән соң, әлеге Таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны раслый.

15. Муниципаль органнар әлеге Таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар кабул ителгән көннән алып 7 эш көне эчендә әлеге хокукый актларны билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыралар.

16. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актларга үзгәрешләр кертү, аларны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә, гамәлгә ашырыла.

17. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы муниципаль органнары, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләре) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары гомуми таләпләрнең 4 пунктында каралган мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

18. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районының муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары гомуми таләпләрнең 5 пунктында каралган мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

19. Заказчылар тарафыннан Зеленодольск муниципаль районының муниципаль органнары, муниципаль казна, бюджет учреждениеләре сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләренә) һәм (яки) Зеленодольск муниципаль районының муниципаль органнарның, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарның таләпләрен раслый торган муниципаль хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен тикшерү муниципаль финанс контроле органнары белән сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг барышында гамәлгә ашырыла.